УДК 351.852.13

*О.Л. Улемнова*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СЫНЛЫ СӘНГАТЬ МУЗЕЕ ТУПЛАНМАСЫНДА ИЛЕБЕЗНЕҢ 1910–1920 ЕЛЛАР АВАНГАРД СӘНГАТЕ

В статье раскрываются этапы формирования и особенности сложившейся в Государственном музее изобразительных искусств Республики Татарстан коллекции отечественного авангардного искусства. Коллекция включает произведения как ведущих российских мастеров авангарда, так и художников Казанской губернии (с 1920 г. – ТАССР). Начало собранию было положено в художественном отделе Центрального музея ТАССР в 1920-е гг., когда сформировалось ядро коллекции русского авангарда и началось формирование коллекции казанских авангардистов. Продолжилось в 1960-е – 1970-е гг. в Музее изобразительных искусств ТАССР (с 1992 – ГМИИ РТ), образованном на базе этого отдела. С этого периода акцент в формировании сместился в сторону казанского искусства 1920-х гг. В результате в ГМИИ РТ сложилась одна из крупных коллекций отечественного авангарда, отражающая особенности развития столичного и регионального авангардного искусства.

**Ключевые слова:** изобразительное искусство, формирование коллекции, русский авангард, региональный аспект, ГМИИ РТ.

Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеендагы (ТР ДССМ) рус авангарды коллекциясе музей тупланмасының горурлыгы санала. Ул рус сәнгате тарихына теркәлгән тасвирый сәнгать, графика һәм скульптура өлкәсендә XX гасырның күренекле рәссамнары В.В. Кандинский, П.П. Кончаловский, А.В. Куприн, А.В. Лентулов, Н.С. Гончарова, М.Ф. Ларионов, Н.К. Рерих, П.В. Кузнецов, Р.Р. Фальк, К.Ф. Богаевский, В.В. Рождественский, И.И. Машков, А.М. Родченко, Д.П. Штеренберг, С.Т. Коненков, Б.Д. Королёв һ.б. хезмәтләреннән гыйбарәт. Музей коллекциясе рус авангарды үсешенең барлык этапларын да (элгәрләре М.А. Врубель һәм В.Э. Борисов-Мусатов иҗатыннан башлап, Европаның һәм рус сәнгатенең символизм, кубизм, футуризм, абстракционизм, примитивизм һәм башка яңа агымнарын) чагылдыра. Алар «Голубая роза», «Бубновый валет», «Ослиный хвост» кебек рус һәм «Синий всадник» халыкара берләшмәләре осталары иҗатында гәүдәләнә.

Академик һәм реалистик сәнгатькә оппозиция рәвешендә формалашкан, үзләренең рус сәнгати программаларын игълан иткән, кайчак үз иҗади юнәлешләреннән баш тарткан, үзенчәлекле алымнары белән публиканы гаҗәпләндергән рус авангардчылары кыска гына вакыт эчендә Европа модернизмы вәкилләре казанышы белән баетылган зур үсеш юлы үтә; дөнья сәнгатенең радикаль формаларына

башлап юл сала. Музей тупланмасында шулай ук авангардчыларның тоталитар режим шартларында, 1930–1940 еллардагы соцреализм хакимлеге чорында (И.И. Машков, П.П. Кончаловский, Р.Р. Фальк һ.б. осталар әсәрләрендә) художество теленең трансформацияләнү күренешләре да чагылыш таба. ТР ДССМндагы рус авангарды коллекциясендә Н.С. Гончарова, В.В. Кандинский, П.П. Кончаловский, А.В. Куприн, М.Ф. Ларионов, А.В. Лентулов, И.И. Машков, А.А. Осмеркин, В.В. Рождественский, Р.Р. Фальк кебек күренекле осталарның рәсем сәнгате, графика һәм скульптура буенча 80 нән артык әсәре саклана. Авангардчы рәссамнарның башлангыч чордагы импрессионистик иҗатын, аларның 1920 елларның икенче яртысы – 1930 еллар башындагы хезмәтләрен, шулай ук 2 нче дулкын рәссам-символистлар К.Ф. Богаевский, П.В. Кузнецов, Н.Д. Милиоти, Н.К. Рерих, Н.Н. Сапунов, М.С. Сарьян, П.С. Уткин һ.б.ның әсәрләрен дә истә тотканда, ул күрсәткеч 150 гә җитә. Коллекциядә рәсем сәнгате белән графика бер дәрәҗәдә, әмма графика өлешендә исемнәр саны азрак, чөнки Д.П. Штеренберг, А.М. Родченко һәм В.Ф. Степанова гравюралары серияләп, П.В. Кузнецов, К.Ф. Богаевский иҗаты – ташбасма альбомнар, И.И. Машков һәм Р.Р. Фальк рәсемнәре монографик коллекцияләр рәвешендә тәкъдим ителгән. Скульптура исә Б.Д. Королев, С.Т. Коненков, И.С. Ефимов композицияләрен генә (барысы – 3) тәшкил итә.

ТР ДССМндагы рус авангарды коллекциясе 1920 елдан – Казан фәнни-сәнәгый музее 1919 елда Казан губерна музее, аннан (1920 елда) Татарстан АССР Үзәк музее дип үзгәртелгәннән соң – формалаша башлый. Бүгенге рус сәнгате коллекциясен тулыландыруда Музей эшләре һәм сәнгати-борынгы заман истәлекләрен саклау буенча Бөтенроссия коллегиясе, шулай ук Мәгариф халык комиссариатының тасвирый сәнгать бүлеге Дәүләт музей фонды (ДМФ) зур роль уйныйлар (аңа кадәр музейда бу өлкәгә караган материаллар бөтенләй булмый). ДМФ 1920 елда музейның сәнгать бүлегенә танылган рус рәссамнарының (беренче чиратта иң яңа сәнгати агымга иярүчеләрнең) күп кенә хезмәтләрен тапшыра. Нәкъ менә шулар арасындагы Б.Д. Королев, С.Т. Коненков, И.С. Ефимовның 3 скульптурасы, күренекле рус авангардчыларының һәм тагын А.В. Грищенко, М.В. Ле Дантю, А.И. Мильман, Н.В. Синезубов, Б.А. Такке, әле зур танылу яуларга өлгермәгән осталарның 40 тан артык тасвирый әсәре Казандагы рус авангардчылары коллекциясенең төп өлешен тәшкил итә. Тапшыру процессы музейның 25 еллыгы (1920 елның апреле), Казан дәүләт сәнгать остаханәсе (Элеккеге Казан сәнгать мәктәбе) бинасында Дәүләткүләм беренче фән һәм сәнгать күргәзмәсен уздыру уңаеннан берничә мәртәбә оештырыла. Соңыннан рус авангардчыларының аларда күрсәтелгән экспонатларыннан күбесе музейның сәнгать бүлеге тупланмасына өстәлә.

Рус авангарды коллекциясе 1920 елларның икенче яртысында – 1930 еллар башында тагын да киңәя: 1927 һәм 1929 елларда ДМФ ннан анда Д.Д. Бурлюк, М.С. Сарьян, В.Э. Борисов-Мусатов, П.С. Уткин рәсемнәре, шулай ук Д.П. Штеренбергның 3 ксилографиясе күчереп урнаштырыла. Шушы ук елларда П.В. Кузнецов белән К.Ф. Богаевскийның басма графикасы альбомы да шул тупламага тапшырыла. 1930 елда анда Дәүләт Рус музеennan да Н.К. Рерихның, Н.Д. Милотти, Н.И. Альтман, Н.И. Кульбинның берничә рәсеме килеп ирешә: 1932 елда дәүләт Третьяков галереясыннан М.Ф. Ларионов һәм В.В. Кандинский хезмәтләре тапшырыла (алар Рәсем сәнгате музее таратылганчы, шул музейда саклан-ган булалар).

Рус авангарды коллекциясенең алдагы киңәю этабы 1958 елда Музейны яңадан үзгәртеп кору белән бәйле була, анда ул сәнгать бүлегеннән мөстәкыйль Сынлы сәнгать музее статусы ала һәм 1968 елда үз бинасына күчә. 1970–1980 еллар рус авангарды осталарының әсәрләрен аларның варисларыннан табып алу активлашкан чор була. Әйтик, 1969 елда Е.М. Бебутовадан – П.В. Кузнецов, 1975 елда М.И. Машковадан И.И. Машковның 7 һәм тагын 3 рәсем сатып алалар; 1985 һәм 1987 елларда А.В. Щекин-Кротова музейга 2 тасвирый сәнгать әсәре һәм Р.Р. Фалькның 45 рәсемен сатып бирә; 1988 елда музей В.А. Родченкодан А.М. Родченко белән В.Ф. Степанованың график композицияләрен сатып ала.

Россия музейларындагы иң эре саналган рус авангарды коллекциясе әнә шулай формалаша, аның туплану юлларын тулырак итеп өйрәнүчеләрнең берсе – Г.А. Могильникова [Русское искусство…, 2005]. Әлеге коллекция рус авангарды сәнгате үсешенең төп тенденцияләрен һәм аның Р.Р. Фальк һәм И.И. Машков кебек осталарының эволюциясен чагылдыра. 1980 еллардан башлап, бу коллекция ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның даими экспозициясенә әверелә һәм Россиядә дә, чит илләрдә дә рус авангардчылары әсәрләре күргәзмәләрен һәрвакыт зур кызыксыну белән карыйлар. Шундый күргәзмәләрнең кайберләрен әйтеп китү урынлы булыр: «1910–1930 елларда рус һәм совет сәнгате» (Турку, 1989); «В.В. Кандинский» (М.-Л. – Франкфурт на Майне, 1989); «В.В. Кандинский Россиядә» (СПб. – Флоренция, 1993); «Мәскәү – Берлин» (Берлин, 1005–1996; М., 1996); «Авангард амазонкалары» (Берлин, 1999; Лондон – Венеция – Бильбао, 2000; Нью-Йорк – Москва, 2001); «Зәңгәр роза – рус символизмы» (Брюссель, 2005–2006; М., 2006); «Футуризм – радикаль революция. Италия – Россия» (М., 2008); «Гасыр даһие» (Казан, 2017) һ.б.

Казан авангардчы рәссамнары әсәрләре коллекциясен әлеге зур тупланманың логик дәвамы дип әйтергә кирәк. Казан сәнгатендә авангардлык юнәлешләре үсеше фәкать 1910 еллар ахырыннан гына башланып,

1930 елларга кадәр дәвам итә. Казан авангардын, кыска гына вакыт эчендә һәм авыр шартларда, рус һәм Европа авангарды формаларының үзара йогынтысы белән һәм шуларның синтезын татар милли традицияләре белән баетып үстерелгән, үзенә генә хас төсмерләргә ия тулы бер күренеш дип бәяләргә мөмкин. «Көнбагыш» («Подсолнечник»), «Җайдак» («Всадник»), «ТатЛЕФ», «СулФ» иҗади берләшмәләре рәссамнарының сакланып калган әсәрләре аларның Европа сәнгате авангарды яулаган иң яңа казанышларны үзләштерүен күрсәтә. Казан «Сул фронт» тарафдарлары рәсем сәнгатендә, станок һәм китап графикасында, плакат һәм театраль декорация сәнгатендә югары нәтиҗәләр яулыйлар, монда аларның экспериментальь театрлар, шагыйрьләр һәм язучылар, әдәби һәм сәнгать әсәрләре тәнкыйтьчеләре белән якыннан хезмәттәшлеге дә зур роль уйный, чөнки алар иҗади хезмәтләрне тикшереп бәялиләр, җитешсезлекләрне ачыктан-ачык күрсәтәләр, кыскасы, яңа хадожество теле табарга ярдәм итәләр.

Казан авангарды коллекциясендә бүген 30 лап рәсем, 600 дән артык график әсәр һәм берничә скульптура берәмлеге исәпләнә. Графиканың өстенлеге Казан рәссамнарының авангардлыкка омтылышы көчле булу белән бәйле.

Казан авангардының музей коллекциясе формалашу ул юнәлешнең үз үсеше белән параллель бара. 1919 елдан башлап, Казан губерна музеенда И.Н. Плещинский, Н.С. Шикалов, К.К. Чеботарев, А.Г. Плутонова, С.С. Федотов, В.Э. Вильковиская, И.А. Никитин, соңрак – Ф.Ш. Таһиров, Н.М. Сокольский, Б.И. Урманче һ.б. кебек күренекле рәссамнарның рәсемнәре, скульптура, графика әсәрләре урын ала.

Сәнгатьтә формализмга каршы көрәш 1930 елларда үзенең иң югары ноктасына җитә, ул осталарны да, аларның күп кенә әсәрләрен дә кызганмый. Сталин чоры дәвере репрессияләренә Б.И. Урманче, С.С. Федотов, И.А. Никитин әлегә, И.Н. Плещинский, М.И. Меркушев, К.К. Чеботарев, А.Г. Плутонов, М.В. Барашев, Ф.Ш. Таһиров, А.Н. Коробкова, В.Э. Вильковиская, Н.С. Ломоносов, Е.А. Александров һ.б. Казаннан китәргә мәҗбүр булалар. Яңа художество телен эзләү белән бәйле әсәрләрнең безнең көннәргә килеп җитүен могъҗиза дип әйтергә кирәк. 1929 елда кулга алынган Б.И. Урманче хезмәтләрен аның шәкерте М.З. Кәримов саклап калган. Г.И. Сотонина АРХУМАС өйрәнчекләре гравюралары оттискларын, ташларга дип, график остаханәсенә бикләнгән хәлдә табып ала һәм аларны К.К. Чеботаревка (1910–1920 еллар Казан сәнгать тормышының елъязмасын туплаучы) тапшыра. Ә менә С.С. Федотов белән М.И. Меркушевның Казанда уздырылган күргәзмәләрдә зур кызыксыну уяткан абстракт рәсемнәре сакланмаган. Сәнгатьнең 1930 еллар башында актуаль саналган бу яңа төре үрнәкләрен иҗат иткән И.А. Никитин һәм Н.М. Сокольский фотомонтажларын да журналларда,

яки махсус басмаларда гына күрергә була.

1960–1970 елларда сынлы сәнгать музее Казан авангардчылары әсәрләре коллекциясен тулыландыруны дәвам итә. Анда К.К. Чеботарев һәм А.Г. Платунова хезмәтләре өстәлә. График коллекция туплау җанланып китә (бу төр сәнгать әсәрләренең төп өлеше иске музей (хәзер ТР Милли музее) фондларында сакланып калган була). Казан авангардының 1920 елларда бу шәһәрдән күчеп китәргә мәҗбүр булган рәссамнары һәм аларның варислары белән тыгыз элемтә урнаштыру бу процессның барышына ярдәм итә. 1978–1979 елларда 1920 еллар Казан графикасын киң яктырткан күргәзмәләр циклы оештырыла, шуннан соң музейга сәнгать әсәрләре сатып алына, шулай ук рәссамнар үзләре, яки аларның туганнары күп кенә хезмәтләрне бүләк итеп бирәләр. Шуның нәтиҗәсендә, һәм алардан тыш та, ТР ДССМ тупланмасында Казанның графика осталары И.Н. Плещинский, Ф.Ш. Таһиров, А.Н. Коробкова, Д.Н. Красильников, М.В.Барашев, К.К. Чеботарев, А.Г. Платунова һ.б.ның монографик коллекцияләре барлыкка килә.

Совет хакимиятенең беренче елларында музей хезмәткәрләре тарафыннан тупланган Казан сәнгате коллекциясе 1990 елда «Искусство Татарии 20–30-х годов. Сулф. Леф. Тат. АХРР» дигән зур күргәзмәдә (ул ТР ДССМда уздырыла) тәкъдим ителә. Экспозиция, шул чордагы традицион реалистик юнәлешләр буенча иҗат итүче авангардчы рәссамнарның каршылыклы иҗатына бәйле рәвештә, республика сәнгатендәге күптөрлелекне һәм каршылыклы юнәлешләрне чагылдыра. Күргәзмәнең каталогы [Каталог выставки…, 1980] ватан сәнгатенең берничә дистә еллар дәвамында сәнгать белеме өлкәсеннән читтә калып килгән әлеге катламын өйрәнүдә мөһим чыганак ролен үти.

ТР ДССМның күргәзмәләр оештыру һәм материаллар туплау эшчәнлеге 1990–2000 елларда Казан авангарды коллекциясен тулыландыруны дәвам итәргә мөмкинлек бирә. Моңа 2005 елда Мәскәүнең «Арт-Диваж» галереясында һәм ТР ДССМ нда уздырылган «АРХУМАС: казанский авангард 20-х» күргәзмәсе зур этәргеч ясый [АРХУМАС: казанский…, 2005]. Казандагы «Җайдак» («Всадник») графика коллективының әз тиражлы басма әсәрләре коллекциясе (1920 елларда ТАССР Үзәк музее туплаган ул басмалар ТР Милли музеенда сакланып калган) шуның тәэсирендә формалаша. Шуны да әйтергә кирәк, андый сәнгати басма берәмлекләр бик сирәк һәм алар бүген дә югары даирәләрдә зур ихтыяҗ белән файдаланыла. ТР ДССМ графиканы туплап бастырган «Җайдак» («Всадник») альманахының барлык 4 санын да (1990 елларда 1 нче саны А.И. Новицкийдан, 2005 елда 2 нче саны Б.М. Мөхетдиновтан; 2005 елда 2 нче һәм 3 нче саннары И.Д. Логиновадан) табып алуга ирешә. Аерым авторларны тулыландыру А.Г. Платунова, И.Н. Плещинский, шулай ук 2005 елда И.Д. Логиновадан

алынган альбомнар ярдәмендә башкарыла. 2005 елда А.А. Романович А.Г. Платунова һәм К.К. Чеботарев рәсемнәре коллекциясен бирә. Соңгы елларда музейга килеп ирешкән сәнгати кыйммәтле табыш – А.Г.Платунова тарафыннан 1925 елда иҗат ителгән «Портрет К.К. Чеботарева» хезмәте (аны 2005 елда И.И. Галиев бүләк итә).

2005 елдан башлап Казан авангардчылары рәсемнәре ТР ДССМ бүлекчәләрендә, «Хәзинә» Милли сәнгать галереясында күрсәтелә. Бу юнәлештә иҗат итүче рәссамнарның күргәзмәләре Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә оештырыла. Аларның иҗади мирасы үзебезнең илдәге һәм хәзер инде чит илләрдәге зур музейлар тупланмалары һәм экспозицияләре составында да тәкъдим ителә. Мәсәлән, К.К. Чеботарев белән Н.С. Шикалов әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясының XX гасыр рус сәнгате экспозициясендә, И.Н. Плещинский рәсемнәре һәм гравюралары Украинаның Киевтагы Милли сәнгать музее даими экспозициясендә тәкъдим ителә. А.С. Пушкин исем. Дәүләт сынлы сәнгать музееның графика фондларында һәм Рус Дәүләт музеенда «Җайдак» («Всадник») рәссамнарының әз тиражлы басмалары, гравюралары һәм аларның такталары саклана [Улемнова].

Болар барысы да Казан авангардчыларының җитди иҗади казанышларын дәлилли, аларның авангардчылык сәнгатендә рус һәм Европа формаларының катлаулы синтезын татар милли традицияләре белән баета белгән үзенчәлекле иҗатын раслый. 2013 елда ТР ДССМ ндагы үзебезнең ил авангардчылары хезмәтләрен туплаган коллекцияләрнең ике өлеше дә федераль кысаларда оештырылган, күптомлы басмаларны да эченә алган «Татарстан сәнгате хәзинәләре» («Художественные сокровища Татарстана») проектында тәкъдим ителде [Казанский авангард, 2014; Русский авангард…, 2014). Бүген һәркемгә мәгълүм булган «рус авангарды» төшенчәсе традициягә әверелгән билгеле бер исемнәр һәм символлар җыелмасын гына күздә тотса, 1920 еллар Казан авангардчылары сәнгате бу юнәлештә Мәскәү һәм Петербург рәссамнары билгеләгән чикләрнең күпкә киңрәк булуын күрсәтә, моны соңгы елларда тәкъдим ителгән күргәзмәләр һәм басмалар да раслый.

**Әдәбият**

АРХУМАС: казанский авангард 20-х. Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан, г. Казань. Галерея «Арт-Диваж», г. Москва. 28 апреля – 6 июня 2005 / авт.-сост. и авт. вст. ст. И.И. Галеев, О.Л. Улемнова. М.: Скорпион, 2005. 168 с.: ил.

Казанский авангард 1910–1930-х: из серии «Художественные сокровища Татарстана» / авт. вст. ст. О.Л. Улемнова, сост. кат. С.Е. Новикова, О.Л. Улемнова. Казань: Заман, 2014. 112 с.: ил.

Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов: к 70-летию образования ТАССР. Государственный музей изобразительных Р.Г. Шагеева, Д.Т. Садыкова. Казань, 1990. 96 с. : ил.;

Русский авангард 1900–1920-х: из серии «Художественные сокровища Татарстана» / Авт. вст. ст. О.Л. Улемнова, сост. кат. О.Г. Вербина, С.Е. Новикова, О.Л. Улемнова. Казань: Заман, 2014. 112 с.: ил.;

Русское искусство XVII – начала XX веков. Живопись. Каталог. Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан / Автор-составитель Г.А. Могильникова. Казань: Изд-во «Казань-Kazan», 2005.

*Улемнова О.Л.* Графический коллектив «Всадник». 1920–1924. Каталог выставки «Сметая веками насевшую пыль...». Казань, 2014. 264 с.: ил.

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*



Гончарова Н.С. Шабат. 1909–1910 (?).
Киндер, майлы буяу. 137,5×118



Кандинский В.В. Импровизация. 1913.
Киндер, майлы буяу. 120×139



Ларионов М.Ф. Провинция көязе. 1907.
Киндер, майлы буяу. 94×67



Рождественский В.В. Натюрморт.
Трактир савыт-сабасы. 1909. Киндер,
майлы буяу. 97,8×85,4



Лентулов А.В. Пейзаж. 1910 еллар.
Киндер, майлы буяу. 65×59



Кузнецов П.В. Бохара малае. 1912–1915.
Киндер, майлы буяу. 63,5×49,5



Чеботарёв К.К. Кызыл Армия. (Марсельеза (Fortissimo)). 1917–1918. Катыргы, темпера. 81,5×101



Александров Е.А. Наданлыкны бетерү. 1927. Киндер, майлы буяу. 105×70



Красильников Д.Н. Г. Кутуйның «Безнең курай» китабы тышлыгына эскиз. 1926. Кәгазь, тушь, гуашь. 21,7×14,8



Тагиров Ф.Ш. «Сулдан юл» плакаты. 1920 еллар. Кәгазь, гуашь. 72,5×53,5



Мухамеджанов Ш.Н. Б. Доминовның «Рәсем ясарга өйрән» китабы тышлыгына эскиз. Вариант. 1929. Кәгазь, тушь, каләм, гуашь, аппликация. 17,8×9,8



Платунова А.Г. Солничка. «Өчәү» альбомыннан бер бит. 1922. Кәгазь, линогравюра. 22,3×15,2; 16,8×11,5



Плещинский И.Н. Бүлмәдә. 1922. Кәгазь, линогравюра. 29×22,1; 16,5×13,4



Чеботарёв К.К. Ленин үлде, компартия яши. 1925. Кәгазь, линогравюра. 33,5×31,5; 32,1×30,4